وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

6+

№16 (159). 19 октябрь 2012 / 4-зөлхиҗҗә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ






Кешеләрне Исламга ничек дөрес үгетләргә?

▷ 2,4 ◁



Самирага җылылык нуры бүләк итик!

▷ 3 ◁



Бәйрәм бүген...

▷ 4 ◁

## Якынлашып килүче Корбан бәйрәме белән!

### Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

**Татарстан Республикасы мөселманнары Дирия нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык дин кардәшләребезне дә иң олы һәм мөбарәк бәйрәмнәрнең берсе булган Корбан гаете белән котлыйм! Елга бер мәртәбә була торган күркәм бәйрәмебез - Корбан гаете барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын!**

Әлеге олуг бәйрәмне барча мөселманнар түземсезлек белән көтеп алалар. Корбан гарәпчәдән "якынаю", "якын булу" дип тәрҗемә ителә. Корбан чалу - кешеләр өчен Аллаһ тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган вә безгә кушып калдырылган изге гыйбадәтләрнең берсе. Әлеге бәйрәм көннәрендә Аллаһы Тәгаләнең бөеклегенә, Исламның хак дин булуына тагын бер кат инанабыз. Мөселманнар, Ибраһим пәйгамбәребезнең (гс) юлын дәвам итеп, рухи-әхлакый камиллеккә, бер-берсенә хәерхаһлы булуга ирешә.

Без бу мөбарәк бәйрәмдә Гает намазларын укып, Аллаһ ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһның рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олуг бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз.

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула. Әлеге бәйрәм авыруларга, бәла-казаларга юлыккан мөселман кардәшләребезгә, олы буын вәкилләренә, ятимнәр һәм мохтаҗларга битараф калмаска, аларга игътибар күрсәтергә чакыра.

Бу мөбарәк көн дошманлык һәм үпкә хисләрен бетерә. Иманнарыбызны, ниятләребезне һәм гамәлләребезне пакьләндерергә, начарлыклардан, явызлыклардан арынырга ярдәм итә.

Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсә иде. Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булсын!

**Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## КОРБАН ГАЕТЕ ВӘГАЗЕ

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһил ләзи һәдәнә лил-иймән вәссаләәтү вәссәләәму галәә расүүлиһи Мүхәммәдин сәййидил әнәми үә гәләә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.**




Безнең күңелләребезне иман, ислам нуры белән нурландырган Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә чиксез хәмед һәм шөкраналарыбыз булса иде. Бөтен мәхлукатның хәерлесе булган, безгә бу дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булырга өйрәткән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи үә сәләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Хөрмәтле мөселманнар! Елга бер мәртәбә була торган бөек бәйрәмебез - Корбан гаете барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын! Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә ил-көннәребезгә, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык, күңелләребезгә тәүфыйк-һидаять биреп, һәркайсыбызга хәерле һәм бәрәкәтле тормышлар насыйп итсә иде. Мөкатдәс Корбан бәйрәме көннәрендә ихлас күңелдән изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, корбаннарыбызны чалып Аллаһы Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә насыйп булсын!

Аллаһ Раббыбыз мәчетебезгә Корбан гаете вәгазен тыңларга һәм Гает намазын укырга дип килгән кардәшләребез һәм төрле сәбәпләр аркасында Гает намазына килә алмаганнарыбыздан, һәркайсыбыздан догага мохтаҗ булган барлык әрвахларыбызның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен гафу итеп, рухларын шат кылса иде.

"Корбан" сүзе нәрсәне аңлата соң? "Корбан" гарәпчәдән "якынаю", "якын булу" дип тәрҗемә ителә. Без бу мөбарәк бәйрәмдә Гает намазларын укып, Аллаһ ризалыгы өчен корбаннар чалып, игелекле гамәлләр кылып, Аллаһның рәхмәтенә якынаябыз, шуңа күрә бу олуг бәйрәмебезне шатланып каршы алабыз.

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре сөю, хөрмәт, бер-беренә миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула. Бу мөбарәк көнне нәфрәт һәм ачулар юкка чыга, дошманлык һәм үпкә хисләре бетә.

Хөрмәтле мөселманнар! Аллаһның рәхмәтенә якынайта торган изге Корбан бәйрәме тирән мәгънәгә ия. Гарәпчә бу бәйрәм "Гыйд әл-әдха" дип атала. "Әдха" сүзе "корбан чалу" дигәнне аңлата. Мәгълүм булганча, корбан чалу йоласы безгә Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнән калган. Без корбан чалганда шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгел, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Бу хакта Аллаһ Раббыбыз Коръәндә Үзе әйтә: "Аларның (корбанга чалынган хайваннарның) ни ите, ни каны Аллаһка түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына ирешә" ("Хаҗ" сүрәсенең 37 нче аяте).

Тәкъва булган, Аллаһны чын күңелдән сөйгән кеше корбанны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларны һәм күршеләрне, фәкыйрьләрне һәм мескеннәрне хөрмәт итә, аларның күңелләрен күтәрә. Шулай итеп, ул Аллаһның ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кыла. Коръәни-Кәримдә әйтелгән: "Әй иман китергән кешеләр, гөнаһ эшләп, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аңа якынлашырга юллар эзләгез, Аның юлында җиһад кылыгыз (тырышыгыз): бәхеткә ирешерсез" ("Маидә (Табын)" сүрәсенең 35 нче аяте).

Мөхтәрәм җәмәгать! Һәрбер мөселман үзенең Раббысына омтылырга, Аны искә алырга, һәрбер гамәлне Аның ризалыгы өчен кылырга тиеш, чөнки ул бары тик Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте аркасында яши. Аллаһы Тәгаләгә якынаю юлларының берсе - хаҗ гыйбадәте. Хаҗ гыйбадәте һәрбер хәлле мөселман өчен фарыз (тиешле) гамәл булып тора. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай дип әйтә: "Мөмкинлекләре булган кешеләрнең Аллаһы Тәгалә каршындагы бурычы - Аның йортына хаҗ кылу" ("Әл-Гыймран (Гыймранның гаиләсе)" сүрәсенең 97 нче аяте).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә әйткән: "Әгәр берәү хаҗ кылып, бозыклык кылмаса, өенә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр", - дигән (Бохари, Мөслим, Нәсаи).

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Әгәр без Аллаһ газабыннан котылырга һәм Аның рәхмәтенә ирешергә, бәхетле булырга телибез икән, Ислам юлында тырышырга, ягъни Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәр көнне гөнаһлардан сакланып, Аллаһка шөкрана кылып, күбрәк игелекле гамәлләр эшләп яшәргә тиешбез.

Аллаһ Раббыбыз Адәм балаларын күркәм сурәттә яратып, акыл, зиһен биреп, барлык мәхлуклардан өстен кылган. Аллаһы Тәгалә Җир өстендә һәм астында булган байлыкларны, судагы хисапсыз күп балыкларны, барлык җан ияләрен безгә буйсынучы, итагать итүче итеп яраткан. Безгә, адәм балаларына бернинди мәхлукка бирелмәгән хәлифә дәрәҗәсе бирелгән. Инде Аллаһ Раббыбыз безне шундый

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### МӘЧЕТЛӘР ФУТБОЛ ЯРЫШЫНДА КӨЧ СЫНАШТЫ

**14 октябрь көнне Казан шәһәренең Үзәк стадионы янәшәсендәге Футбол-җиңел атлетика манежында "Нык иманлы" исемендәге кубокка башкала мәчетләре арасында футбол буенча ярышлар үтте.**

Ярышларны Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, "Зәкят" хәйрия фонды, Казан шәһәренең физик тәрбия һәм спорт комитеты, Кабан арты мәчете һәм "Алтын урта" татар-мөселман яшьләре җәмгыяте оештырды.

Чараны Изге Коръәннән аятьләр уку белән башлап җибәрделәр. Соңыннан "Зәкят" хәйрия фонды җитәкчесе Сәетҗәгъфәр хәзрәт Лотфуллин, Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдин, Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге белгече Рафаэль хәзрәт Мифтахов һәм "Алтын урта" татар-мөселман яшьләре җәмгыяте җитәкчесе Акйолдыз сәламләү сүзе белән чыгыш ясадылар.

Ярышларда 9 команда катнашты. Мәрҗани мәчете - III урынны, Кабан арты мәчете - II урынны алды. I урынга "Әниләр" мәчете командасы лаек булды.

Җиңүчеләр медаль һәм грамоталар, шулай ук "Нык иманлы" кубогы белән бүләкләнде. Командадагы һәр кешегә бүләкләр тапшырылды.

Бүләкләр тапшыру тантанасында Сәетҗәгъфәр хәзрәт Лотфуллин, Нурислам хәзрәт Ибраһимов, Рафаэль хәзрәт Мифтахов, Казан шәһәренең физик тәрбия һәм спорт комитеты башлыклары катнашты.

### БӘЙРӘМГӘ – ЯҢА МӘЧЕТ

**21 октябрьдә Биектау районының Каенлык авылында "Хәсән-Хөсәен" мәчете ачылу тантанасы үткәреләчәк.** Мәчетне Биектауда гомер кичерүче Балтач егете Габделнур Хөсәенов төзеткән. Тантанага Татарстанның баш казые, күпсанлы дини китаплар авторы Җәлил хәзрәт Фазлыев, Габделнур әфәнденең әтисе Хәсән Хөсәенов, район җитәкчеләре чакырылган. Мәчет күп еллар дәвамында Бөрбаш, Сәрдегән авылы мәчетенең мәзине булып торучы Хәсән ага исемен йөртәчәк.

Мәчет ачылышының тантаналы өлешен оештыручы, бәйрәмнәр алып баручы Гамил Нур хәбәр иткәнчә, мәчет бинасы ике катлы. Ул үз эченә гыйбадәт залыннан тыш, башлангыч мәдрәсә һәм аш бүлмәсен алып тора. Кызыл кирпеч белән тышланган бу бина Ислам мәдәнияте үзәге ролен үтәячәк.

### НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ ТЕЛЕФОНГА КИЛӘ

**Казанлылар хәзер намаз вакытларын телефоннарында йөртә ала, шушы максатта www.allah-akbar.ru сайты эшли башлады.**

Сайтны төзүче Марат Биктимеров сүзләренә караганда, әлеге проект кешеләргә намаз вакытлары турында даими хәбәр итеп тору өчен эшләнгән. Намаз вакытлары телефонга килеп торсын өчен, сайтка кереп телефон номерын калдырырга кирәк. Номерыгызны җыйганнан соң, "язылу" кнопкасына басасыз, ике хәбәр килә, беречесе - сәламләү "сүзе", икенчесе - шушы көнгә намаз вакытлары. Намаз вакытларыwww.dumrt.ru сайтыннан алына.


### ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# КОРБАН ГАЕТЕ ВӘГАЗЕ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

олуг нигъмәтләр белән бүләкләгәннән соң, безгә зур гына вазифалар, бурычлар йөкләгән. Коръәни-Кәримдәге "Тәхрим" сүрәсенең 6 нчы аятендә адәмнәр өстендәге олуг вазифаларның кайберләре искә алына. Шул вазифаларны үтәмәүчеләрнең каты газапка дучар булачаклары турында белдерелә: "Әй иманлы бәндәләр, үзегезне һәм гаиләгезне уттан саклагыз. Ул утның утыны кешелек вазифаларын, кешелек бурычын үтәмәгән адәмнәр булыр".

Шулай итеп, Аллаһ Раббыбыз бу аять белән безгә белдерәдер ки, үзебезне һәм гаиләбезне дөнья, ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган начар эшләрдән тыеп, җәһәннәм газабыннан сакларга куша. Өстебездә булган зур бурычларыбыз хакында Рәсүл әкрам галәйһиссәлам үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: "Әй бәндә, синең өстеңдә Раббыңның хакы, нәфесең һәм әгъзаларыңның хакы бар һәм гаиләңнең хакы бар, һәрбер хак иясенә хакларын бир, вазифаларыңны үтә".

Әлеге вазифаларны, динебез күрсәткән бурычларны аңлап китик әле.

Беренче вазифа - Раббыңның хакы. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә каршында булган вазифалар, ягъни дөньяны, барлык галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһны тану, биргән барлык нигъмәтләренә шөкрана кылып, һәрвакыт һәр җирдә Аллаһ хозурына барып, хисап бирәчәгебезне истә тоту.

Икенче вазифа - акылын гыйлем белән баету адәм баласының бурычы. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: "Белем алу - һәрбер мөселман өчен фарыз (тиешле)" (Ибн Мәҗә).

Мөселман кешесе, дөньяви гыйлемме, дин гыйлемме - икесен дә тигез күреп өйрәнергә бурычлы, чөнки дөньяви гыйлем белән дини гыйлем, үзара бәйләнгән рәвештә, бер-берсен тулыландыра.

Өченче вазифа - кешенең тагын бер вазифасы, ягъни Аллаһ биргән тән сәламәтлеген саклау. Авыру булса - дәвалану. Күп кенә тән авырулары дөрес тукланмаудан килә. Бүгенге көндә без чамадан тыш күп ашыйбыз һәм эчәбез, ашказаннарыбызга ял бирмибез. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам ашказанын өчкә бүләргә кушкан: бер өлеше - ризык, бер өлеше - су, бер өлеше һава өчен (Тирмизи). Аллаһ Раббыбыз бу хакта Үзенең китабында да әйткән: "Ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми" ("Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсенең 31 нче аяте).

Дүртенче вазифа - адәм баласының иң җитди бурычларының берсе - күңелен, җанын тәрбияләп, аны начар сыйфатлардан арындырып, күркәм сыйфатлар белән бизәп, бөтен кешеләр белән дустату, тыныч торырга һәм игелекле гамәлләр кылырга тырышу. Рәсүл әкрам галәйһиссәлам әйткән: "Аллаһы Тәгалә сезне тышкы кыяфәтегез һәм матди байлыгыгыз буенча бәяләмәс. Ул сезнең күңелләрегезгә (калебләрегезгә) һәм сез кылган гамәлләрегезгә карый" (Тәбарани).

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: "Белегез, кеше тәнендә бер ит кисәге бар, әгәр ул сәламәт булса, бөтен тән сәламәт булыр, әгәр ул авыру булса, бөтен тән авыру булыр. Белегез ки, ул ит кисәге - калебтер" (Бохари, Мөслим).

Бу хәдисләрдән күренгәнчә, динебез калебкә зур әһәмият биреп, аңа игътибарлы булырга боера. Һәр мөселман үз калебенә хуҗа булырга тиеш. Калебләребезне сафландыру - һәрбер мөселманның изге бурычы.

Иң гүзәл калебләр - иман, ислам нуры белән нурланган, күркәм гамәлләр белән бизәлгән һәм һәртөрле гөнаһтан сакланган сөенечле калебләр. Аларга ия булучылар ике дөньяда да бәхеткә ирешәчәк. Шуңа күрә мөселман һәрвакыт һәм һәр урында калебне каралта торган гамәлләрдән ерак торырга тырыша. Киресенчә булса, ул үзен олы куркынычка илтә. Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: "Мөэмин бер гөнаһ эшләгән вакытта аның калебендә бер кара тап барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итеп, бу гөнаһтан ваз кичсә, аның калебе пакьләнә. Әгәр ул тәүбә итмәсә һәм гөнаһлы гамәлне кылуны дәвам итсә, аның калебендә кара таплар саны арта һәм калебе каралана"(Ибн Мәҗә).

Түбәндәге аятьләрне истән чыгармыйк: "Җанын пакь тоткан кеше морадына (сәгадәткә) ирешәчәк. Вөҗданын кер каплаган кеше, әлбәттә, хәтәр зыян күрәчәк" ("Шәмес (Кояш)" сүрәсенең 9-10 нчы аятьләре). "Мәгълүмдер ки, Аллаһ турында уйлаганда, Аны зекер иткәндә күңелләр рәхәт тынычлыкка ирешә" ("Рәгыд (Күкрәү)" сүрәсенең 28 нче аяте). "Ул Көнне мал да, угыллар да файда китермәс. Әмма Аллаһка саф күңел белән инанганнар бәхетле булыр" ("Шөгарә (Шагыйрьләр)" сүрәсенең 88-89 нчы аятьләре).

Мөхтәрәм мөселманнар! Шуны һәрвакыт истә тотыйк, изге гамәлләребез Аллаһ тарафыннан кабул булсын өчен калебләребез иманнан башка ихласлык белән дә бизәкләнгән булырга тиеш. Күп санлы изге гамәлләрне ихлассызлык белән үтәүгә караганда, аз санлы гамәлләрне ихласлык белән кылу күпкә яхшырак.

Газиз дин кардәшләрем! Вәгазем ахырында сезне бер риваять белән таныштырып үтәсем килә.

Бөек галим Җүнәйд Багдадига (Аллаһы Тәгалә аны Үзенең рәхмәтеннән аермаса иде) 7 яшь булганда, абыйсы Сарий Сакати аны үзе белән хаҗ гыйбадәтен кылырга алып барган. Әл-Харам мәчете ("Изге мәчет" дигән сүз) эчендә, ягъни Кәгъбәтулла янында төрле мәсьәләләр буенча сөйләшүләр барган, шуларның берсе шөкрана кылу турында булган. Анда катнашкан һәр шәех бу турыда үз белем-тәҗрибәләре белән уртаклашкан. Сарий Сакати Җүнәйдкә борылып, аңа шөкрана турында үз фикерен белдертергә кушкан. Бераз уйлагач, 7 яшьлек Җүнәйд түбәндәге гаҗәеп матур җавапны биргән: "Шөкрана кылу - ул Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы булмау, Аның нигъмәтләрен файдаланып, шулар белән гөнаһ кылмау".

Мөхтәрәм җәмәгать! Без Аллаһ Раббыбыз биргән әгъзаларыбыз белән дә гөнаһ эшләмәскә тиеш. Күзебезне хәрам булган нәрсәләрдән, телебезне - гайбәттән, ялганнан, яла ягудан, буш сүзләрдән саклыйк. Телләребез белән күбрәк Аллаһны искә алыйк, файдалы, дөрес сүзләр сөйлик. Карыныбызны хәрам ризыклардан, кулларыбызны хәрам гамәлләрдән, аякларыбызны Аллаһның ачуын китерә торган җирләргә барудан саклыйк. Хәдис-шәрифтә болай диелгән: "Файдасыз эшләрдән качу - яхшы мөселманның билгесе" (Тирмизи).

Аллаһы Тәгалә барчабызга да ихлас шөкрана кылучылардан булырга, күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалыначак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт тормышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде.

**(Вәгазьне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы Нияз хәзрәт САБИРОВ әзерләде)**

# КЕШЕЛӘРНЕ ИСЛАМГА НИЧЕК ДӨРЕС ҮГЕТЛӘРГӘ?

**Кеше ниндидер бер җир кисәге алып анда үзенә йорт төзер өчен гомере буе эшли. Бу дөньяның иң йогынтылы кешеләренә дә, андагы бар байлыкларга да хуҗа булырга мөмкинлек бирелмәгән. Бу дөньяның бар байлыкларына ия булсалар да, алар аның рәхәтлекләре белән барыбер бик озак файдалана алмаслар иде.**

Аллаһы Тәгалә безгә күп тапкырлар азрак тырышлык күрсәтеп, бу дөнья, аның бар байлыкларыннан күпкә зуррак кыйммәтләргә ия булган башка байлыкка ия булырга мөмкинлек биргән. Бу байлыклар иясе, җир байлыкларыннан аермалы буларак, алар белән мәңге файдалана алу мөмкинлегенә ия.

Шуңа да карамастан, күпләр Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән мәңгелек бу рәхәтлекләргә ирешүгә ваемсыз карый. Бүгенге көндә үгетнәсыйхәткә мохтаҗ күпме кеше бар, ә без аларга игътибар бирми яннарыннан үтеп китәбез. Ә алар үзләрен мөселманга исәпләсәләр дә, үзебезнең танышлар арасында да имансызлыкта яткан кешеләр күпме?! Чынбарлыкта, аларда Исламнан ата-аналары кушкан исемнәре генә калган кешеләр дә бар бит. Тирәбездә Аллаһы Тәгалә кушкан бурычларын үтәмәгән, лаеклы тормыш алып бармаган, күп гөнаһлар кылган күпме кеше - ә без алар яныннан битараф үтеп китәбез.

Без савабын алмавыбызны белсәк тә, әллә утка ташланган таныш түгел кешегә дә ярдәм итмәс идекме?! Шул ук вакытта без утка, дөньяви уттан күпкә куркынычрак утка ташланучы якыннарыбызны күреп торабыз, тик барыбер битараф калабыз. Бу безнең иманнарыбызның камил булмавы билгесе түгелмени?

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисендә: "Тугры юлга үгетләүче аның артыннан баручылар кадәр үк савабын алыр, бу аның (үз) савабын һич тә киметмәс", - диелә.

Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән әҗеренең бик аз гына өлешен булса да без бу дөньяда алган булсак, кешеләрне Аллаһның юлына өндәргә теләүчеләр бик күп булыр иде.

Кешеләрне хак юлга үгетләр өчен теләк булу гына җитми. Аллаһ юлына чакыручы билгеле бер сыйфатларга ия булырга тиеш, югыйсә ул туры юлга чакыру урынына кешеләрне Исламнан биздереп куярга мөмкин.

***Рәсүлуллаһ (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): "Әгәр дә Аллаһ синең аркылы бер кешене тугры юлга җибәргән икән, бу синең өчен бөтен дөнья, андагы бар әйберләргә караганда да яхшырак", - дигән.***




Бөек фарсы шагыйре һәм фикер иясе Җәләлетдин Руминың ямьсез тавышлы бер мөәзин турында кызыклы бер хикәяте бар. Аның бу тавышыннан ялыккан халык бу мөәзиннән котылырга карар иткән. Алар юллык акча җыйганнар да, бу кадәр дә сөйкемле тавыш белән сиңа бары тик Мәккәнең үзендә генә эшләргә кирәк дип, бу мөәзинне ышандырганнар. Һәм дә бу мөәзин кәрван белән юлга чыккан. Аларга христианнар илендә төн үткәрергә туры килгән, ястү намазы вакыты җиткәч, бу мөәзин үзенең шул котсыз тавышы белән намазга чакыра башлаган. Иртә белән алар янына бу христиан шәһәреннән берәү бүләкләр тотып килгән. Аның кызы Ислам кабул итәргә ниятләгән булган икән, ә аның әтисе аны бу ниятеннән ничек кире кайтарырга белми, ди. Бу кыз төнлә әлеге мөәзиннең тавышын ишетеп, нинди шөкәтсез тавыш бу дип кызыксынган. Аңа шулай итеп мөселманнар намазга чакыралар дип аңлатканнар. Шуннан инде бу кыз Ислам кабул итү уеннан кире кайткан. Шул шатлык уңаеннан аның атасы мөәзинне бүләкләргә булган икән.

Шул мөәзин кебек булып калмас өчен, без Аллаһ юлына өндәүченең нинди сыйфатларга ия булырга тиеш икәнен белергә, һәм дә ул сыйфатларга туры килергә тиешбез.

Без монда дин юлына өндәүченең дүрт төп сыйфаты турында сөйләшербез. Аллаһ юлына чакыручы һәр инсан аларны истә тотарга тиеш.

## Гыйлем

Гыйлем - безнең динебезне төзегән төп нигез. Гыйлеме булмаган кеше сукырга тиң. Ә сукыр туры юлдан бара аламы соң?

Әлбәттә, без барысыннан да шәригать галимнәре булуларын таләп итә алмыйбыз. Һәм бу мәкалә дә, нигездә, бар гомерен фән өйрәнеп үткәргән галимнәр өчен язылмаган, ләкин белемнәрнең билгеле бер минимумына һәркайсыбыз да ия булырга тиеш. Кемне дә булса без ниндидер яхшы гамәлгә өндибез икән, без бу мәсьәлә буенча белемебезне тирәнәйтергә тиешбез. Мәсәлән, сезгә бер танышыгызны җомга намазына йөрергә күндерергә кирәк, ди. Җомга намазына йөрү фарыз икәнен барыбыз да белә, тик бу өлкәдә сезнең бар гыйлемегез шуның белән генә чикләнә икән, сезгә бу танышыгызны җомга намазына йөрү зарурлыгына күндерү авыр булачак. Әгәр дә инде сез Коръәни-Кәримдә, хәдисләрдә бу намазның кыйммәтлелеге турында, җомга намазын калдыручыларны нинди җәзалар көтүе турында ниләр язылуыннан хәбәрдар булсагыз, сезнең ул үз танышыгызны күндерү өчен мөмкинлекләрегез күпкә артачак кына. Бүгенге көндә дин өлкәсендәге һәр мәсьәләгә тиешле җаваплар бирә торган китапларны табу кыен түгел. Шуның өстәвенә, вәгазьләр, лекцияләр белән гаять зур сандагы аудио һәм видеоматериаллар да бар. Башта иренми генә, башкаларны үгетли торган теманы яхшы гына өйрәнегез, моннан сезнең дәгъват кылуыгызның нәтиҗәлелеге күпкә артачак кына.

Башкаларны ниндидер гамәлләргә өндәүче кешеләргә гыйлемгә ия булу гына җитми, булган белемнә-

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Дәүләтнең дини сәясәтендә – либеральләштерү

*(Ахыры. Башы газетабызның 12 октябрь (№15) санында.)*

Авылларда профессиональ дин әһелләре җитмәү үзен нык сиздергән. Элекке дин әһелләренең дини йолалар башкаруларда катнашулары турында үз отчётларында билгеләп үтеп, СРК вәкиле: "Алда әйтеп кителгән сукбай муллаларның гамәлләре турында минем тарафтан җирле органнарга җиткерелде. Аларның исемлеген мин, аларга табыш салымы салу предметы буенча тикшерергә финанс органнарына бирәм", - дип яза.

Мөселманнарга дини йолаларны башкару өчен, еш кына, күрше авылларда рәсми теркәлү алган гыйбадәт йортлары булуына сылтау ясап, үз авылларында рөхсәт бирмәгәннәр. Андый "күршелек" ун яки аннан да күбрәк чакрымнар санында да булырга мөмкин булган. "(Хәзерге Башкортстан Республикасының Чишмә районындагы. - ред.) Келәш авылы мөселманнары, дүрт чакрымдагы Каран-Елга авылына (шул ук районда. - ред.) йөрергә теләмиләр, ә тәтешлеләр, унбиш чакрымдагы Сәйтәк авылына (хәзерге Башкортстан Республикасындагы Балтач районына керә. - ред.), тимкәнекеләр - шулай ук Сәйтәккә, шулай ук 15 чакрымга", - дип зарлана вәкил.

Мөселманнарның дини тормышында изге Мәккәгә хаҗ кылуны яңадан торгызу зур вакыйга була. 1945 елның 26 октябрендә мөфти Габдрахман Рәсүлев мөселманнарга: "Хөкүмәт, мөфти җитәкчелегендәге 17 кешелек мөселман төркеме төзеп, 1945 елның декабрендә хаҗ кылырга барырга рөхсәт бирде", - дип игълан итә. Хаҗ кылып кайтканнан соң мөфти зәмзәм чишмәсеннән алынган изге суны мөселманнарга таратуны оештыра.

1947 елда барлык Диния нәзарәтләрен дә (Үзәк, Урта Азия, Төньяк Кавказ, Кавказ арты) кертеп, 40 кеше хаҗ кылырга бара. Хаҗ кылырга бару һәм аны оештырырга рөхсәт алу бик четерекле була.

1946 елны СРК исә "... Ирандагы авыр һава шартлары, автомобиль һәм тимер юллар булмавы һәм диңгез юлының ышанычсыз булуы аркасында" рөхсәт бирми. Ә 1948 елда хаҗга бару "гарәп илләре арасында сәяси мөнәсәбәтләрнең катлаулануы һәм Иранда ваба авыруы таралуы" аркасында булмый кала. Хаҗ кылырга баручылар саны нык чикләнә, анда баручылар кырыс сайлап алу һәм куркынычсызлык органнарының тикшерүләрен үтәләр, һәм аннан тыш, күпләрнең хаҗ кылырга бару өчен җитәрлек акчалары да булмый.

Илнең мөселман регионнарында шактый сандагы изге урыннар булган. Ул изге урыннарга зиярәт кылырга мөселман бәйрәмнәрендә һәм мондый көннәрдә дә мөселманнар килә торган булган.

Андый зиярәт кылулар Бөек Ватан сугышы елларында аеруча популяр булган.

Мөселманнарның зиярәт кылулардагы активлыгы аларда дини традицияләрнең нык булуы турында да сөйли. Хакимият органнары исә бу изге урыннар дин әһелләренә һәм дини оешмаларга зур табышлар бирә һәм дини карашларның ныгуына китерә дип исәпләгәннәр.

Сугыштан соңгы чорларда илдәге Исламның хәлен тикшергән вакытта, бар дин әһелләренең дә, бер искәрмәсез дип әйтерлек, шул ук вакытта, рәсми теркәлү алмаган мәчет мулларын да кертеп, өлкән яшьтәге кешеләр булганлыгын әйтми калу мөмкин түгел. Дини белемнәрне, имам-хатыйб исемнәрен алар XX гасыр башында ук, Беренче бөтендөнья сугышына кадәр үк алган булганнар.

Сугыштан соң инкыйлабка кадәр эшләп килгән күпсанлы мәдрәсәләрнең берсе дә калмаган, алар ябылып беткәннәр. Илдә мөселман дин әһелләре әзерләүче бердәнбер уку йорты Бохарадагы "Мир-Араб" мәдрәсәсе булган. Ләкин Татарстан өчен анда беркем дә укымаган.

Андый вазгыять мөселманнарны, Үзәк Диния нәзарәтен, мөфти Габдрахман Рәсүлевнең үзен борчымый калмаган. Алар имамнар әзерләү өчен СРКга 30 кешелек кыска сроклы дини курслар булса да ачарга рөхсәт сорап, берничә тапкыр мөрәҗәгать иткәннәр. Укыту программасы әзерләнгән, ул программага Коръәнне, хәдисләрне, дин кагыйдәләрен, ислам этикасын, СССР Конституциясен укыту кертелгән.

1946 елда Г.Рәсүлев СССРның Министрлар Советы каршындагы СРКга җәйге курслар булса да ачуны рөхсәт итүне сорап гариза юллый. Әмма курслар ачылмый кала, чөнки "... бу курсның тыңлаучылары, уку вакытында үзләрен тәэмин итә алмыйлар", диелә.

1948 елда кабул ителгән мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәтенең уставы киләчәктә нинди дә булса дини уку йортларын булдыру мөмкинлеген бөтенләй юкка чыгара. Узган гасырның 30 нчы ел репрессияләрен кичергән өлкән яшьтәге профессиональ дини кадрлар елдан-ел кимиләр, аларга алмашка кешеләр булмый.

Мөселманнарның күп өлешенең дини тормышы, күрүебезчә, я тыелган, я хакимиятнең бар урыннарына да үтеп керә торган күзәтүе астында булган. Тик, шуңа да карамастан, ул яшәвен дәвам иттергән. Ул гына да түгел, сугышның соңгы елларында импульс алып, Башкортстандагы дини тормыш инерция буенча үсешен дәвам иткән.

Бу очракта, тикшерү алып барган чорда динилекнең саклануы һәм алга таба үсүенә китергән факторларны күрсәтеп үтәргә кирәк.

1. Чамасыз газаплар һәм халыкка зур корбаннар китергән Бөек Ватан сугышы елларында, узган гасырның 30 нчы елларындагы репрессияләр чоры белән ил халкын нык кыскан хакимият алдындагы курку хисе юкка чыккан. Илне тышкы дошманнардан азат итү халыкның рухи хөрлек алуы белән бергә барган.

2. 1943-1948 елларда хөкүмәтнең дини сәясәт өлкәсендә азмы-күпме либеральләшүе күзәтелә, мөселманнарга һәм дин әһелләренә өлешчә ташламалар ясала. 1946 елның 26 гыйнварында кабул ителгән карар хакимиятнең дин сәясәте өлкәсендә җибәргән хата һәм ялгышларын тануга дәлил итеп кабул ителгән. Һәм дә бу ялгышларны халык киң күңел белән гафу итәргә әзер булган. Мөселманнарда дини активлыкның күтәрелүе башланган, ул гыйбадәт йортларын, дини җәмгыятьләрне яңадан торгызуда чагылыш тапкан.

3. Динилекне саклау һәм аны кире торгызуда мөһим фактор булып дини кадрларның, инкыйлабка кадәр үк күпсанлы авыл мәктәп һәм мәдрәсәләрендә - ул вакытларның урта һәм югары дини уку йортларында тулы кыйммәтле белем алган кадрларның сакланып калуы булган. Аларның күбесе тоткынлыкта булып кайтсалар да, куркуларын җиңеп, дини эшчәнлекләрен дәвам итәргә әзер булганнар.

4. Ниһаять, дини кануннарны, кагыйдәләрне, йолаларны белү - халыкның үзендә дә сакланып калган. Ислам, тормыш рәвеше буларак, ике буын вәкилләреннән торган күп гаиләләрнең тормыш-көнкүрешендә сакланган.

Соңгы ике фактор, безнең карашка, аеруча әһәмиятле булган. Нәкъ менә белемле дин әһелләре буынының, шул ук вакытта, гаиләдә традицион дини белем алган кешеләрнең табигый юкка чыгуы белән, дини тормышның әкренләп сүрелүе күзәтелә дә. Ә бу дини сүрелү, котылгысыз рәвештә узган гасырның 70 нче елларындагы дини кризиска - ул елларның рухи кризисына китергән.

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы**

# Самирага җылылык нуры бүләк итик!



***Гайнетдинова Самира Линар кызы 2010 елның 3 декабрендә туган. Сабый - игезәкләрнең берсе; кызлар вакытлары җитмичә - 7 айлык булып туганнар. Балалар үз яшьләренә карап үскәннәр, ләкин 6 айлык вакытта Самираның сеңлесеннән артта калуын сизгәннәр. Табибка баргач, котычкыч диагноз куелган: ДЦП (балаларда була торган церебраль паралич). Бүген аларга 1 яшь тә 10 ай. Кызганыч, Самира әле дә булса үрмәләп йөрү сәләтенә ия түгел һәм үзе генә утыра-тора алмый; аның күзләре дә начар күрә (ике күзнең дә күрү нервларында өлешчә атрофия, күрү анализаторының үзәк бүлеге ялкынсынуы). Кыз күп тапкырлар Казанның һәм Мәскәүнең неврология хастаханәләрендә, шулай ук Украинаның профессор Козявкин исемендәге Тернәкләндерү клиникасында дәваланган. Самираның әтиәнисе һәрвакыт балаларының сәламәтлеге өчен көрәшә. Алга китеш бар, ләкин ул сизелер-сизелмәс кенә бара.***

***Бүген көндә бердәнбер юл - Самирага ярдәм итәргә мөмкинлек бар. Ул әнисе белән Кытайга - Аркан-Байвин клиникасына китәчәк, шунда дәвалану курсы узачак. Кирәк булган акчаның бер өлеше җыелган инде, тик тагын 225 мең сум җыясы калды.***

***Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге "Туган авылым" ресторан-күңел ачу комплексы һәм Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтаховның матди ярдәме белән "Самирага җылылык нуры бүләк итик!" исемле фотоакция оештыра.***

***Фотосессиядән җыелган барлык акчалар да Гайнетдинова Самира Линар кызының исәпхисап счётына күчереләчәк.***

***Яхшы сыйфатлы фотосессия ясарга, шулай ук Самирага ярдәм итәргә теләүчеләрне 27 октябрь көнне "Туган авылым" ресторан-күңел ачу комплексында көтеп калабыз. Адресы: Казан шәһәре, Луковский ур., 14 нче йорт. Акциянең үткәрелү вакыты - иртәнге уннан (10.00) кичке сәгать бишкә (17.00) кадәр. Фотосессиянең бәясе - бер мең сум (15 эшкәртелгән фотосурәт өчен).***

**БАРЛЫК СОРАУЛАР БЕЛӘН ДӘ ТҮБӘНДӘГЕ ТЕЛЕФОННАР БУЕНЧА ЭЛЕМТӘГӘ КЕРӘ АЛАСЫЗ:**
***8 (843) 2646158, 89872639889 (ГӨЛНАРА).***

# Казанда корбан чалу өчен махсус мәйданчыклар булдырылачак

**Корбан гаете мөселманнар өчен зур әһәмияткә ия булган бәйрәмнәрнең берсе булып тора. Әлеге бәйрәм Зөлхиҗҗә аеның унынчы көненә туры килә (2012 елның 25 октябре), алдагы өч көн (26, 27 һәм 28 октябрь) Тәшрикъ көннәре булып саналалар.**

Корбан гаете бәйрәм намазы белән башланып китә. Татарстанның барлык мәчетләрендә дә алты тулып утыз минутта (6.30) иртәнге намаз укылачак, җиде тулып унбиш минутта (7.15) бәйрәм вәгазе башланыр, дип көтелә. Сәгать сигездә (8.00) - бәйрәм (гает) намазы.

Һичшиксез, Корбан гаетенең төп вакыйгасы булып корбан чалу тора. Быел да Казан шәһәрендә, шәһәр мэриясе белән килешенеп, корбан чалу өчен махсус урыннар билгеләнәчәк. Мәрҗани мәчете каршындагы комплекс һәм Бертуган Петряевлар урамындагы махсус мәйданчык шушы максатта кулланылачак. Казан мөхтәсибәтеннән хәбәр итүләренчә, Казаннан читтә урнашкан бистәләрдәге мәчетләрдә дә, корбан чалу өчен барлык шартлар да булдырылган очракта, шулай ук корбан чалып булачак (әйтик, Казан нуры, Сөләйман мәчетләрендә).



# КЕШЕЛӘРНЕ ИСЛАМГА НИЧЕК ДӨРЕС ҮГЕТЛӘРГӘ?

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

реңне дөрес итеп файдалана да белергә кирәк. Ул кешеләрнең холкын белергә тиеш, аларның интеллект дәрәҗәсен исәпкә алырга, үгетләр өчен кулай урын һәм вакыт сайлап ала һәм бу вакытта әңгәмәдәше белән ни турыда сөйләшергә отышлырак икәнен чамалый белергә дә тиеш.

Хәдисләрдә: "Кешеләр белән аларның аң дәрәҗәсен исәпкә алып сөйләшегез", - диелгән. Көтүче белән сөйләшкәндә, мәсәлән, сүзне хәдисләрне аңлату фәне турында башларга кирәкми, бу аңа кызыклы булмаска мөмкин. Аны кызыксындыра торган темалар табарга кирәк. Бәлки сүзне Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзе һәм күп кенә башка билгеле кешеләр дә сарыклар көткәннәр дип башлап җибәрергә кирәктер. Әгәр дә әңгәмәдәшең тарихчы икән, аның белән бу фән турында да сөйләшергә була, чөнки бу тема тарих белән бәйле һәм дә бу тема аны, һичшиксез, кызыксындырачак. Әгәр дә инде, бу тарихчы Исламда тарихи вакыйгаларны аңлатуга нинди тәфсиллек белән якын килүләрен дә күрсә, бу аны Исламга да китерүче төп фактор булырга да мөмкин.

Дин таратучы үзе мөрәҗәгать иткән җәмгыятьне яхшы белергә тиеш. Теләсә кайсы һөнәр буенча да, яңа эшли башлаган һөнәрче ярдәмчесеннән остазлар эшләгән кебек үк эш нәтиҗәләре таләп итеп булмаган кебек үк, гөнаһларга баткан кешедән дә, аның диннең бар кагыйдәләрен, йолаларын да камил башкаруын таләп итү мөмкин түгел. Аны мондый халәткә әкренләп китерергә кирәк.

Бер көтүче фарыз намазларын укымый калдырган дип сөйлиләр. Аны ничек кенә үгетләмәсеннәр, моны башкарырга вакыты калмау белән ул үзен-үзе аклый икән. Аның белән танылган бер галим очрашып сөйләшкән. Галим кеше, көтүченең намаз укымаганын һәм ни өчен укымаганын белгәч, аннан сораган:

- Таң атканда, көтүгә чыкканчы, син намаз укый аласыңмы?

- Әйе, - дигән көтүче.

- Ә кояш баюга син көтүдән кайтасыңмы? - дип сораган галим.

- Әйе, - дип җавап биргән көтүче.

- Ул вакыт син ахшам намазын укый аласыңмы?

Көтүче галимнең дәлиле белән килешкән.

- Ә йоклар алдыннан син тагын бер намаз укый аласыңмы? - дип сораган галим.

- Әлбәттә, - дигән көтүче.

Шулай итеп көтүче көненә өч тапкыр намаз укый башлаган. Шуннан кешеләр арасыннан кемдер бу галим көтүчене көненә өч тапкыр гына намаз укырга өйрәткән дип хәбәр тараткан. Голамә җыелышларының берсендә, бу галимне бераз гына "чеметеп" алырга ниятләп, берәү аннан: "Син, чынлап та, бер кешене өч кенә тапкыр намаз укырга өйрәттеңме?" - дип сораган. Галим аңа:

- Бу кеше бөтенләй намаз укымый иде һәм беркем дә аны фарыз намазларны укырга күндерә алмады. Мин аны биш фарыз намазның өчесен булса да укырга өйрәттем. Сез монда кырыклап укымышлы кеше бит. Калган икесен генә булса да, сез үз өстегезгә алыгыз, - дигән.

Бу галим әлеге көтүчене биш вакыт намаз укырга күндерә алмавын аңлаган, чөнки аңа кадәр моны эшләп караучылар моңа ирешә алмаганнар. Ул шул ук вакытта, әгәр дә ул бу кешене фарыз намазларның бер өлешен генә булса да укырга күндерә алса, ул калганнарын аннан соң укый башлаячагын аңлаган. Изгелек изгелекне тарта, явызлык - явызлыкны. Әгәр дә без кечкенә генә кар кисәген йомарлап таудан тәгәрәтеп төшереп җибәрәбез икән, бераз вакыттан соң ул зур кар өеменә әйләнәчәк. Шулай ук, без кемнедер даими рәвештә нindидер бер изге гамәл кылырга үгетли алабыз икән, ул гамәлләр аны башка изге гамәлләр кылуга да тартачак.

Шул ук вакытта үгетләр өчен кулай урын һәм вакытны да сайлый белергә кирәк. Хак юлдан тайпылган кеше гомеренең күп өлеше сәрхүшлек халәтендә үтә. Мин исерткеч эчемлекләр белән сәрхүш булуны күз алдында тотмыйм, гәрчә андыйлар аз булмаса да, бу фани дөньяның азгынлыклары белән сәрхүш булу турында сүз бара. Кеше күңеле хакыйкатьне чагылдыручы көзге кебек ул. Әгәр дә бу көзге тузан белән капланган икән, анда берни дә күренми. Һәр кылынган гөнаһ күңелдә кара эз калдыра, аннан соң күңел тулысынча шундый эзләр белән капланып бетә, һәм аңа иман нуры үтеп керә алмый башлый. Ләкин һәркемдә дә айнуга якын мизгелләр була. Нигездә, мондый халәт кешегә ниндидер кайгы килгән вакытта, бигрәк тә аның берәр якын кешесе вафат булганда, яки кеше үзен ялгыз итеп хис иткән вакытта була. Мондый вакытларда кеше вәгазь һәм үгет-нәсыйхәтләрне бөтенләй башкача кабул итә башлый, һәм дә бу вакытта аның янында аңа ярдәм итеп, аны Аллаһ юлына өнди торган кем дә булса берәү табылса, бу кешенең мондый чакыруларга уңай җавап бирү ихтималлыгы күбрәк була.

## Күркәм холыклылык һәм гадел тормыш алып бару

Хәдисләр буенча, күркәм холыклылык Хисап көнендә үлчәүләргә салынганның иң зур үлчәмлесе. Әгәр дә нинди дә булса бер кеше, гыйлемнәргә ия булып та, күркәм холыклы булып гадел тормыш алып бармаса, ул башка кешеләрне хак юлдан биздерәчәк кенә. Кешеләрнең күпчелеге хакыйкать турында бу кешенең ни сөйләгәненә карап түгел, ә аның тәртибенә, үз-үзен тотышына карап фикер йөртә.

Исламның дошманнары бу турыда бик яхшы беләләр һәм мөселманнарны аздыру, юлдан яздыру һәм аларны башкалар алдында явыз һәм канэчкеч ерткычлар итеп күрсәтү өчен күп акчалар тоталар.

Тәкъваларның берсе: "Әгәр дә мөселманнар үз-үзләрен тиешенчә тотсалар, барысы да инде күптән Исламга күчеп беткән булыр иде инде", - дигән.

Күптән түгел генә гарәп телеканалларының берсендә, ниндидер бер Африка илендә, бер сәүдәгәр аркасында илле мең кеше Ислам кабул итүе турында тапшыру караган идем. Бу сәүдәгәр бу ил авылларының берсендә бер кибетне арендага алган икән. Һәм бу авыл кешеләре бераз вакыт үткәч, бу сәүдәгәрнең күркәм холкын һәм юмартлыгын күреп Ислам кабул иткәннәр. Аларга күрше-тирә авыллардагы кешеләр дә ияргән. Әгәр дә бу авылда, Исламны күтәрәбез дигән булып (хәзер кайберәүләр моны эшләгән кебек) үлемдарлар тарафыннан шартлатулар оештырылса, бу кешеләр Ислам кабул итәрләр идемени?

Әгәр дә без тарихка күз салып, Исламның ничек таралыш алуын күзәтсәк, сәхабәләр һәм табигыйннар чорыннан соң, кешеләрне Исламга тартуның төп казанышы суфиларныкы икәнен күрербез.

Әле борынгы вакытта ук Җаһиз: "Шигырьне камилләштерү өчен шагыйрьнең гарәп булуы шарт, ә Аллаһ юлына чакыручы өчен - аның суфи булуы шарт", - дип юкка гына билгеләп китмәгән инде.

Хәтта Исламның иң явыз дошманнары да мондый гадел һәм тәкъва кешеләр белән очрашып сөйләшкәч, Ислам кабул иткәннәр һәм гомерләрен Исламны таратуга багышлаганнар. Моның иң ачык чагылышына мисал итеп, бәлки, монгол империясе хакимнәренең Ислам кабул итүен китерергә буладыр.

Ибн Батута Алтын Урда җирләренә сәяхәтнамәсендә Ислам кабул иткән бу илнең хакиме Үзбәк турында, аның суфи шәехе Ногманетдин әл-Харәзми белән мөнәсәбәтләре турында яза. Ибн Батута сүзләре буенча, ул заманнарның иң бөек хакимнәреннән исәпләнгән Үзбәк хан, һәр җомгада шәехкә килә торган булган, басынкы гына аның каршына килеп тезләнеп, аның белән юаш кына итеп сөйләшә торган булган. Алтын Урданың тагын бер хакиме, Чыңгыз ханның оныгы - Бәркә хан, Сәйфетдин әл-Бәхәрзи шәехне күрергә һәм аның мөриде булыр өчен бик зур юл үткән. Шәех янына кергәч, аның аякларын үбеп, үзен аның шәкертләренең берсе итеп алуны үтенгән. Әгәр дә дәһшәтле хакимнәр дә алар кулыннан Ислам кабул иткәнен, аларның шәкертләре булып киткәнен исәпкә алганда, бу шәехләргә гади халыкның нинди мөнәсәбәттә булганын сөйләп торуның, мөгаен, бернинди зарурлыгы да юк.

Ихласлык һәм күркәм холыклылык - суфилар омтылган төп сыйфат менә шулдыр, һәм дә алар бу сыйфатларда камиллеккә омтылганнары аркасында, Аллаһы Тәгалә алар аркылы гаять күп сандагы кешеләрне туры юлга юнәлткән дә.

**(Ахыры газетабызның киләсе санында.)**

**Руслан хәзрәт МОРТАЗИН,**
**Татарстанның төньяк-көнчыгыш төбәге казые**

## *Казанда намаз вакытлары*

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 20.10.12 | 5:55 | 7:25 | 13:02 | 16:01 | 17:31 | 19:01 |
| *Якшәмбе* | 21.10.12 | 5:58 | 7:28 | 13:02 | 15:59 | 17:28 | 18:58 |
| *Дүшәмбе* | 22.10.12 | 6:00 | 7:30 | 13:02 | 15:58 | 17:26 | 18:56 |
| *Сишәмбе* | 23.10.12 | 6:02 | 7:32 | 13:02 | 15:57 | 17:24 | 18:54 |
| *Чәршәмбе* | 24.10.12 | 6:04 | 7:34 | 13:02 | 15:55 | 17:21 | 18:51 |
| *Пәнҗешәмбе* | 25.10.12 | 6:06 | 7:36 | 13:02 | 15:53 | 17:19 | 18:49 |
| *Җомга* | 26.10.12 | 6:08 | 7:38 | 13:02 | 15:52 | 17:17 | 18:47 |
| *Шимбә* | 27.10.12 | 6:10 | 7:40 | 13:02 | 15:50 | 17:14 | 18:44 |






## Бәйрәм бүген...

***Шамил бүген таң белән уянды. Нигә шулай иртә уянды соң әле ул? Югыйсә, кичтән дә бик иртә ятмаган иде?.. Бабасы Дамир аңа кич буе кызыклы хикәятләр сөйләде.***

Өй эче нур белән тулган. Чү! Нинди яктылык соң бу өй эчендә? Ут та янмый, әле кояш та чыкмаган?! Бу яктылык күктән килә кебек иде. Ул тәрәзәләр аша гына түгел, өйнең стеналары аша да керә бугай. Менә:

"Аллаһу әкбәр! - дигән тавыш ишетелде. - Аллаһу әкбәр! Лә иләһә илләллаһү!" Нинди матур тавыш соң бу? "Бәйрәм! - дип уйлады малай. - Бүген бәйрәм бит! Корбан бәйрәме! Чү! Ул бүген бабасы белән иртүк мәчеткә барырга тиеш иде бит! Дусты Наил дә барырга тиеш анда. Дөрес, алар кичә ачуланышканнар иде. Ләкин иртән Шамилнең күңелендә бернинди ачу калмаган иде. Бабасы дөрес әйткән: "Иртәгә Корбан бәйрәменең таңы атканда синең күңелеңдә дустыңа карата бернинди дә ачу калмаячак әле. Күрерсең менә!" - дигән иде. Бабасы мең тапкыр хаклы булган икән. Шамилнең кәефе шәп! Ул бүген беренче тапкыр бабасы белән мәчеткә бара! Ул инде зур малай! Ул инде җиткән егет хәзер!

"Аллаһу әкбәр!" - дип кабатлады Шамил өлкәннәр артыннан. Шул серле сүзне әйткән саен, күңеленнән кабатлаган саен малайның җаны кояш нурлары белән тулган кебек булды. Аның кош кебек очып китәсе килде! Ләкин ул кош түгел, ул - кеше, ул - адәм баласы! Адәм пәйгамбәр исә аның иң ерак, иң беренче бабасы булган! Дамир бабасы шулай дип әйтте! Ә ул әйтсә һәрвакыт дөрес әйтә! Чөнки аның күңелендә Ходай Тәгалә чәчкән нурлар бар! Ул нурлар бүген Шамил күңелендә дә! Урамда бәйрәм бүген! Өйләрдә бәйрәм! Шамил күңелендә бәйрәм: "Аллаһу әкбәр! Лә иләһә илләллаһү..."

**Зиннур ХӨСНИЯР,**
**язучы,**
**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе**

**Бараны на Курбан-байрам. Забой, доставка.Тел.: 89046683857 (Артур)**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 16 (159) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9421.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 18 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклангыз!**